Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге Советы
423050Аксубай районы,ЯңаҮзиавылы Мәктәпурамы, 7 нчейорт

Совет Беловского сельского поселения Аксубаевского муниципального района
423050Аксубаевский район,с.НовоеУзеевоулица Школьная, д.7

Тел. (8-84344-4-08-19) ОГРН 1061665003212,
ОКПО 04306440, ИНН/КПП 1603005000/160301001
E-mail: *Belov.Aks@tatar.ru,sovet.belov@mail.ru*

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Беловка авыл җирлеге башлыгы
КАРАР

№ 3 14.11.2025 ел

**«Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге Алексеевка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Беловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә, торак пунктта гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә , Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге Советының 05.11.2019 ел, № 102 карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында " 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карарына таянып Аксубай районы Беловка авыл җирлеге башлыгы

КАРАРы:

1. 2025 елның 23 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге Алексеевка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: ТР, Аксубай районы, Алексеевка авылы, Зеленая урамы, 21 йорт..
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге Алексеевка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Федерациясенең махсус операцияләрдә катнашучы хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

**1.Җирлекнең халык яшәгән пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге.**

- Беловка авыл җирлеге Алексеевка торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау.(Беловка авыл

җирлеге Алексеевка торак пункты чикләрендә юлны кышкы карап тоту (юлларны кардан чистарту,запас частьләр һәм җайланмалар сатып алу; эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу, поселок юлларын ремонтлау, вак таш кайтару, туфрак һәм вак таш салу һәм тигезләү).

**2.Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлектә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:**

-су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Алексеевка авылында суүткәргеч челтәрен ремонтлау, материаллар сатып алу, тирәнлек насосын ремонтлау һәм алыштыру, шартнамә, эксплуатация чыгымнарын түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Беловка авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Интернет челтәрендәге рәсми сайтында, http://aksubayevo.tatarstan.ru ) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы
Беловка авыл җирлеге башлыгы И.Р.Мәхмүтов